РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«11» ноября 2022г. с. Тюлячи № 239

**Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 28 февралендәге 28 номерлы «Элегрәк хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 28 февралендәге 28 номерлы «Элегрәк хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- күрсәтелгән карар белән расланган, Элегрәк хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына:

а) 3.3.2.1 пунктның 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гарызнамәне формат - логик тикшерү орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүченең һәрбер электрон форма гарызнамәсен тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан башкарыла. Бердәм портал тарафыннан гарызнамәнең электрон рәвештә тутырылган кырының корректлы булмавы ачыкланса, мөрәҗәгать итүчегә турыдан-туры гарызнамәнең электрон формасында ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында мәгълүмати хәбәр ителә.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин